ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

13.03.2026 с.Старое Дрожжаное №8

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Чүпрәле звеносы турында» 2021 елның 20 гыйнварындагы 2 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлектә «ПБ КЧС функцияләре»:

икенче абзацта «янгын куркынычсызлыгы,» сүзләреннән соң «гражданнар оборонасы,» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «, шулай ук гражданнар оборонасы өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «, шулай ук гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итүгә» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясенең гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт программаларын эшләүдә катнаша һәм аларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерли;»;

алтынчы абзацта «, шулай ук гражданнар оборонасы эшчәнлеген» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «, шулай ук гражданнар оборонасы өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацта «күрсәтелгән ЧС» сүзләреннән соң «һәм мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта «һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү» сүзләрен «, янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү» сүзләрен «, янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле **уникенче абзац** өстәргә:

«гражданнар оборонасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

Башлык: М.Р. Гафаров